ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^4$ пункт өстәргә:
«$7^4$) дәүләт мөлкәтен мөмкин булган минималь бәягә сату-алу шартнамәсен төзү тәртибен билгели;»;

2) 13 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 16 статьяның 1 өлешендә «Бәясен игълан итмичә генә» сүзләрен «Мөмкин булган минималь бәягә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 14 июнь
№ 35-ТРЗ